**Илбәк авыл җирлеге Советы һәм Башкарма комитетының**
**2023 елда эшләгән эшләренә йомгак ясау, 2024 елга бурычлар**

Илбәк авыл җирлегенә 4 авыл керә.

Авыл җирлегендә "Азнакай" Агрофирмасы" ның бүлекчәсе һәм бюджет учреждениеләре: башкарма комитет, башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, клуб, медпункт, китапханә, почта хезмәткәре эшчәнлек алып баралар.

1) шәхси хуҗалык саны – 311 ( шунын 130 дача хуҗалыклары) .
2) КФХ юк.
3) индивидуаль эшмәкәрләр – 3.

Авылның демографик ситуациясе:

Барлыгы 266 кеше теркәлгән, эш яшендәгеләр – 135, эшләүчеләр -125, мәктәпкәчә яшьтәгеләр – 15, мәктәп яшендә – 25, студентлар – 12, пенсионерлар – 80.
Туучылар – 1, үлүчеләр саны 3.

| | 01.01.2023 | 01.01.2024 |
|---|---|---|
| Илбәк авыл җирлегендә теркәлгән кешеләр саны | 266 | 266 |
| Илбәк | 173 | 163 |
| Ирекле | 25 | 27 |
| Тархан | 25 | 26 |
| Тырыш | 43 | 50 |

Ирекле, Тархан, Тырыш авылларында яшәү урыны буенча теркәлгән кешеләр саны арту күзәтелә.

Көндәлек эшкә килгәндә:

Авыл советы тарафыннан ел дәвамында районыбызда эшләүче барлык оешмаларга айлык, квартал һәм еллык отчетлар бирелә. Электрон документ алмашы, электрон почта, факс аша килгән хатлар вакытында теркәлеп бара, аларга кыска срокларда җавап бирелә. Гариза нигезендә халыккка 15 төрле муниципаль хезмәт күрсәтелә, былтыр аларның саны **8**. Хуҗалыклардагы кеше саны, мал башы, йорт һәм җир мәйданы, транспорт турында мәгълүмат хуҗалык китабының электрон версиясенә теркәлеп бара. (слайд)

Интернет челтәре көннән-көн җәелгән заманда авыл җирлеге башкарма комитетының эшен дә төрле программалар, сайтлардан башка күз алдына китереп булмый. Һәр хокукый норматив актны, башкарма комитет эшендәге үзгәрешләрне, яңалык-белдерүләрне үз вакытында "Муниципаль берәмлекләр" порталында урнаштыру – бүгенге көн таләбе. (слайд) Теләге һәм мөмкинлеге булган һәркем

әлеге сайтка кереп, Илбәк яки башка авыл җирлеге буенча үзен кызыксындырган информацияне таба ала.

2023 елнын 1 июленә хуҗалыклардагы мал саны түбәндәгечә (слайд):

Мөгезле эре терлек – **31** баш (шул исәптән сыерлар **10** баш), сарыклар – **99**, кәҗәләр – **30 (**шул исәптән 16 савым кәҗә**)**, кош-корт – **2137**, атлар – 2, умарта – **120**. Яз һәм көз көннәрендә ветеринария хезмәткәрләре тарафыннан сыерлардан кан алу һәм малларга вакцина ясау оештырылды. “Азнакай” Агрофирмасы быел пай җирләрен кулланган өчен икмәкләтә түли алды, теләгән кеше былтыргысы өчен дә икмәк алды. (слайд)

2023 елда савым сыерларга һәм савым кәҗәләргә бирелә торган субсидия 2022 нче елдагыча түләнде (слайд):

Әлеге мал ияләренең исемлекләре төзелеп, кирәкле документларын туплап, Авыл хуҗалыгы идарәсенә илтеп тапшырылганнан соң, мал хуҗаларының банк счётларына **36 375** сум күләмендә субсидия күчте (7 сыер өчен 24 100 сум, 13 кәҗә өчен 6 500 сум, 55 үрдәк бибие өчен 5 775 сум).

Мал асраучылар өчен ел әйләнәсе актуаль булган игълан:

Татарстан Республикасының Баш ветеринария идарәсе белән килештермичә, башка өлкәләрдән һәм регионнардан терлек алып керүгә юл куймаска. Карантин чаралар үткәрү өчен яңа сатып алынган хайваннар турында Дәүләт ветеринария хезмәтенә хәбәр итәргә кирәк. Малларны, кош-кортны бары тик барлык ветеринар документлары булган кешеләрдән, оешмалардан гына сатып алырга кирәк. Үзебезне саклыйк, хөрмәтле авылдашлар.

Хәрби исәп буенча эш

Запаста 31 кеше теркәлгән. Язгы һәм көзге чакырылыш – 100% үтәлде, 3егет комиссия үтте.

Паспорт-виза хезмәте

Ел дәвамында 10 кеше теркәлде (шуның 1се – яңа туган бала), 7 кеше исәптән төшерелде (шуның 3 се – үлүчеләр). Паспорт алучылар – икәү. 5 кеше паспорт алмаштырды.

Милекне рәсмиләштерү эше

2022 елда Федераль Закон №518-ФЗ кабул ителде. Шуны үтәү максатыннан республика күләмендә оформить ителмәгән өйләр, җирләр барланды. Шундый милектән файдаланган кешеләргә уведомлениеләр таратылды, очрашулар, телефоннан аңлашулар булды. Нәтиҗәдә 3 җир участогы, 1 өйнең правообладательләре билгеләнде, 6 җир участогы буенча зембюрода эш бара, 2 правообладателнең эше судта тәмамлану алдында. Кызганычка каршы, бу чараларның берсен дә кулланып булмаган очракларда объектлар кадастровый учёттан төшереп калдырылды. Шунын өчен бар булган милекне тиз арада оформить итәргә кирәк. Авыл советы бу эштә сезгә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер.

Милек өчен булган салымнарны җыюны бик зур авырлык белән башкарып чыктык. Мөмкинлеге булган кеше интернет челтәрендә “Госуслуги” порталы аша салымын үзе түләде. Түләнмәгән налоглары, әҗәтләре (пени) булган кешеләрне вакытында салымнарын түләргә өндәр идем. Чөнки салым буенча 1 тиен генә әҗәтең булса да, бу гражданин өчен барлык дәүләт хезмәтләрен алуда киртә булачак. Ягъни пенсия, субсидия ала торган кешенен түләнмәгән әҗәте бар икән, бу кешенең юлга дигән акчасы яки коммуналь түләүләр өчен ала торган субсидиясе түләнмәячәк. Салымнары түләнмәүчеләрне ел дәвамында барлап, аларга аңлату эшләре алып барыла, атна саен район район күләмендә җыела торган комиссиядә шул эшләргә отчет ясала.

Ел дәвамында район башлыгына 1, авыл җирлеге башлыгы һәм район Советы депутатына 4 гражданнар мөрәҗәгате каралды. Алар барсы да уңай якка хәл ителде. Башкарма комитет исеменә булган мөрәҗәгатьләр буенча ел башында отчет ясала, сайтка урнаштырыла (слайдта күрә аласыз).

Гомуми җыелышлар үткәрү буенча

- 20 гыйнварда – Илбәк авылында 2022 ел нәтиҗәләре буенча отчет җыелышы үткәрелде. (слайд)
- 2024 елда үзара салым акчаларын нинди эшләргә тотарга планлаштыру буенча 4 авылда да ноябрьдә халык җыеннары үткәрелде. (слайд)

Ел да 15 апрельдән санитар-экологик икеайлык игълан ителә. Кар эреп бетү белән, өмәләр оештырыла. Юл кырыйлары, авыл эчендәге урамнар, мәчет, һәйкәл, зират буйлары, мәктәп ихатасы җыештырылды. Бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренә, авылның өлкән апалары да бик актив рәвештә ярдәм итәләр. Яз айларында мәктәп, мәчет территориясенә бик куп төрле чәчәкләр утыртылды. Илбәк, Ирекле, Тырыш,Тархан авылларындагы зиратларда зур өмәләр үткәрелде. Бик күп агач киселде һәм чистартылды. Әлеге изге эштә катнашкан барлык кешегә бик зур рәхмәт, бу безнен олы бурычыбыз. Зиратта тәртип саклау һәм мәетләрне соңгы юлга озату зиратны карап торучы Гобәев Флерга өстенә йөкләнгән. Җәй айларында зират эчендәге үләнне улы Рамазан белән кирәк саен чабып тордылар бик зур рәхмәт аларга.

Һәйкәл, зират, амбар тирәләрен пенсионер апалар җыелып җыештырдылар. Алар шулай ук авыл эчендәге баганаларны буяуда да катнаштылар. Ирекле авылы янындагы Миннеәхмәт чишмәсе 2 мәртәбә җыештырылды. (слайд)

Шулай ук ел дәвамында сибиреязвенный скотомогильник һәм биотермик чокырларны санитар һәм эпидемиологик таләпләргә туры китереп чистарту эшләре алып барылды.

Ирекле авылы халкы берничә көн рәттән авыл эчендәге бик күп кирәкмәгән агачларны кистеләр. Аларны төяп чыгару өчен һәм яз айларында авылга су төшмәслек итеп, су юлын ясар очен, хөрмәтле кураторыбыз Айдар Фәндәсович техника белән ярдәм итте.

9 май бәйрәме алдынан һәйкәл территориясе җыештырылды. (слайд) Яз көне апалар җыелышып авылыбызның мәчет ихатасын тәртипкә китереп, чәчәкләр утырттылар. Авылыбызда азан тавышы ишетелеп, мәчетебез җылы, чиста һәм якты булып торсын дип тырышучы Сафиуллинар гаиләсенә рәхмәтемне җиткерәм.

Кыш көне мәчетнең җылыту системасы ватылып, бик зур ремонт эшләре башкарылды. Стенадагы ике контурлы котел идәнгә куела торган котелга алмаштырылды. Монын өчен бөтен вентиляция һәм су торбаларына реконструкция ясалды. Батареяларның барсын да сүтеп кире җыясы булды. Шуларга өстәп, яңа батареялар алынды һәм урнаштырылды. Кышкы салкын көннәрдә Азнакайдан килгән бригада әлеге эшләрне башкарып китте. Барлык кирәк-яракларны сатып алу, башкарылган эш өчен 65 мең сум акча тотылды. Матди ярдәм күрсәткән барлык авыл халкына, читтәге авылдашларга һәм шушы акчаны җыюны оештырган Гыйләҗетдинова Зөлфиягә бик зур рәхмәтемне җиткерәм.

Авыл территориясен чистарту өчен килешү нигезендә Губаев Рамазан эшкә алынды. Ул җәй буе авыл эчендәге, мәчет, мәктәп, зират буйларындагы чүпләрне чапты. (слайд) Шулай ук Ирекле, Тархан, Тырыш авылындагы юл буйлары чабылды.

Авылларыбыз урамнарында бик еш хуҗасыз этләр барлыкка килә. Азнакай шәһәренең МПП БИО оешмасында алар өчен приют оештырылган. Ел дәвамында шул оешмага заявкалар бирелде, һәм тота алган этләрне хезмәткәрләр үзләре белән алып китте. Ләкин бәйсез этләр күбәя. Йорт этләрен бәйдә тотуыгызны сорыйм.

Кыш көне авылыбыз юлларын чистартуда “Азнакай” Агрофирмасы” эшчеләренең ярдәме бик зур. (слайд) Ә кече авылларга килгәндә, анда шәхси эшмәкәрләр белән килешү нигезендә юллар чистартылды.

Яз айларында «Татнефть» ярдәме белән уздырылучы агач утырту программасы нигезендә Илбәк авыл территориясендә 100 меңнән артык агач утыртылды. Бик күп техника һәм кеше җәлеп итеп, бу эшне Саба урманчылык хуҗалыгы башкарды.

2014 елдан бирле авыл җирлекләрендә үзарасалым программасы эшләп килә. Халыктан җыелган 1сум акчага хөкүмәт тарафыннан 4 сум бирелә. (слайд)

Һәрбер авылда эшләнгән эш күренсен өчен, 2019 елдан башлап үзара салым акчаларын шул авылда яшәүчеләр санына карап җыю оештырылган. **2023 елда үзара салым акчасы** түбәндәгечә җыелды: (слайд)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Илбәк | 38 550 | 154 200 | 192 750 |
| Ирекле | 13 300 | 53 200 | 66 500 |
| Тырыш | 18 300 | 73 200 | 91 500 |
| Тархан | 10 000 | 40 000 | 50 000 |
| БАРЛЫГЫ | 80 150 | 320 600 | 400 750 |

## Ирекле авылында 2023 елда үзара салым акчаларының бүленеше

| Чараның исеме | Тотылган сумма |
|---|---|
| Ирекле авылында чишмәне койма белән әйләндереп алу, төзекләндерү (төзелеш материаллары, хуҗалык товарлары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү). | 66 500 |

## Тырыш авылында 2023 елда үзара салым акчаларының бүленеше

| Чараның исеме | Тотылган сумма |
|---|---|
| Тырыш бистәсенең Октябрьнең 70 еллыгы урамында щебенка түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау, юлларга щебенка җәю (сатып алу, транспорт хезмәте, ташу, вак таш җәю һәм тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү) | 50 000 |
| Тырыш бистәсендәге юлларны кардан чистарту | 41 500 |

## Илбәк авылында 2023 елда үзара салым акчаларының бүленеше

| Чараның исеме | Тотылган сумма |
|---|---|
| Илбәк авылы уртасында урнашкан ял итү зонасына койма сатып алу һәм урнаштыру, Ә.Вәлиев һәйкәле территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, койманы ясау һәм урнаштыру, эшкә килешү буенча түләү) | 75 000 |
| Жирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру | 10 000 |
| Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү өчен килешү буенча хезмәт күрсәтү; | 75 000 |
| Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү); | 15 000 |
| Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту | 17 750 |

## Тархан авылында 2023 елда үзара салым акчаларының бүленеше

| Чараның исеме | Тотылган сумма |
|---|---|
| Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту | 50 000 |

**Тырыш** авылының юлларына щебенка җәйдерүгә җыелган акчага МПП И БиО оешмасы белән килешү төзелде . Юлларга профилирование ясау быелгы язга планлаштырылды.

Калган өлеше (41 500) кыш айларында юлларны кардан чистарту өчен тотыла.

**<u>Ирекле</u>** <u>авылында җыелган үзара салым акчасы түбәндәге эшкә тотылды:</u>

- Ирекле авылында 2022 нче елда жыелган акча әз булу сәбәпле, былтыр аңа өстәп акча жыелды. Чишмәләрне төзекләндерү эшен башкарырга бернинди оешма һәм шәси эшмәкәр табылмады. Шунлыктан бу эшне быел башкарып чыгарга ниятләп торабыз. (слайд)

**<u>Илбәк</u>** <u>авылында җыелган үзара салым акчасы түбәндәге эшләргә тотылды:</u>

- Бер өлешенә (75 000 ) - Илбәк авылы һәйкәлен коймалап алу өчен материаллар сатып алынды.

- Массакүләм культура чараларына каралган акча: отчет җыелышында котлау, Сабантуйны үткәрү өчен бүләкләр алу, 9 майда, Өлкәннәр көнендә пакетлар тарату өчен, (слайд), яңа ел бәйрәмен үткәрү өчен тотылды (75 000 сум тәшкил итте).

- Жилэнергосервис белән килешү төзеп, АГП Подъемник машинасын чакыртып, авылда 2 мәртәбә 4 светильник ремонтланды һәм 20 лампочка алмаштырылды. (слайд) Бу сумма 15 000 сум тәшкил итте.

Ел дәвамында я автомат, я светильник янып чыгу сәбәпле, утлар кайвакыт янмый тора. Электрик таба алмыйча бу вакыт озакка сузыла, әмма безгә бу эштә авылыбызда яшәүче Гатауллин Әнәс абый ярдәмгә килде. Бер эндәшү белән, кайчакта әйткәнне дә көтмичә үзе барып тиз арада ТП дагы гаепне табып, төзәтеп тә куя. Бик зур рәхмәт аңа.

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру, чуп чабу 10 000 сум

Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту килешү буенча түләүгә тотылды. (17 750 сум)

2024 елда үзара салым җыю буенча Илбәк, Ирекле, Тырыш авылларында гражданнар җыены үткәрелде. (слайд) Җыен нәтиҗәләре буенча **2024 елда үзара салым акчасы** түбәндәге эшләргә каралды (һәр авылдан 1 кешедән җыеласы сумманы слайдта күрә аласыз):

<table>
<tr><td>Илбәк, 500 сум<br>- традицион күмү урыннарын төзекләндерү (куакларны кисү, экскаватор белән агачларны төпләү, гербидцид сатып алу, гербицид белән химик эшкәртү, эш өчен килешү буенча түләү)<br>- Илбәк авылы җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);<br>- Илбәк торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Ә.Вәлиев, Профсоюзная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү))</td></tr>
<tr><td>Ирекле, 700 сум<br>- традицион күмү урыннарын төзекләндерү (коймалар алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу, нигезен, коймасын урнаштыру)</td></tr>
</table>

| |
|---|
| **Тырыш, 600 сум**<br>- Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тырыш авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Октябрьнең 70 еллыгы урамына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү)) |
| **Тархан, 1 500 сум**<br>- Тархан торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Тархан авылындагы юлларны кардан чистарту; вак ташны сатып алу, ташу, Лесная, Заречная урамнарына вак ташны җәю, эшкә килешү буенча түләү, тракторчыга хезмәт хакын түләү)). |

2022 елда илебезгә сугыш афәте кагылды. Бүгенге көндә авылыбызда яшәмәсә дә, Ситдиков Сәгыйт абый һәм Диләрә апаның улы Ситдиков Венер өлешчә мобилизация кысаларында илебезне сакларга алынды. Бик зур рәхмәт аларга шундый ул тәрбияләгәннәре өчен. Тәрхан авылында яшәүче Нургалиев Эдгар да бүгенге көндә контракт җуенча сугыш кырында хезмәт итә. Яу кырына киткән барча кеше исән-имин өйләренә әйләнеп кайтсыннар дигән теләктә калабыз. Сугыш афәте тәмамланып, бердәм булып, тыныч тормышларда яшәргә насыйп булсын.

Бәла килсә, бөтен ил белән каршы торырга әзер безнең халык. Ил чикләрен сакларга киткән егетләребез өчен җылы оекбашлар, бияләй, муенсалар, аяк киемнәре, эчке киемнәр һәм бүтән кирәк-яракларны җыю берничә тапкыр оештырылды. Шулай ук маскировочный сеткалар ясар өчен жыелып, апаларыбыз 3 төргәк сетка үрделәр, 2 тапкыр токмач җәеп кистеләр. СВО да булган хәрбиләргә райондашлар белән күрсәтелгән ярдәмдә авылдашларыбызның да өлеше зур: барлык азык-төлек һәм башка кирәк-яраклар тиз арада районга илтеп тапшырылды. Шушы эштә катнашкан һәммә кешегә, матди ярдәм генә түгел, йөрәк җылысын да салган барчагызга бик зур рәхмәт.

<u>Бюджет учреждениеләре эшенең торышы</u>

<u>Балалар бакчасына 2</u> бала йөри, 3 хезмәткәр эшли. Балалар көненә 4 мәртәбә кайнар аш белән тәэмин ителгән. Ата-аналар взносларны вакытында түлиләр. Санитар эпидимиологик талэплэргэ туры китереп эшлилэр.

<u>Башлангыч мәктәптә</u> 3 бала укый, 2 укытучы 1 хезмәткәр эшли. (слайд) 6 көнлек уку атнасында, көненә 1 мәртәбә кайнар ризык белән тәэмин ителгәннәр. Быел бер бала укырга керде. Алдагы уку елында да 1 бала керер дип көтелә. Беренче класска керүче балалар белән атнага бер тапкыр әзерлек дәресләре алып барыла.

Мәктәп белән балалар бакчасына продукция тендер үткән ООО “Фудсоцсервис” җәмгыятеннән санитар нормаларга туры килә торган продукция

китерелә. Җәй айларында классларда косметик ремонт ясалды. Уку елы алдыннан районның кабул итү комиссиясе тикшерүләрен үтеп, мәктәп һәм балалар бакчасы барлык таләпләргә дә туры китереп, эшне башлап җибәрделәр. Педагогик коллектив һәм техник хезмәткәрләр авылда оештырылган барлык өмәләрдә, чараларда бик актив катнашалар.

Кәкре-Елга урта мәктәбенә 10 бала йөреп укый. (слайд) Балаларыбыз төрле олимпиада, спорт ярышларында актив катнашалар. Мәктәп администрациясе һәм укытучылар белән даими элемтәдә торабыз.

Фельдшер-акушерлык пунктында 1 хезмәткәр эшли. (слайд) Барлык беркетелгән өлкәннәр саны – 137, балалар – 23. Барлыгы 1 250 кеше кабул ителде, 988е – медпунктта, 262се – өйдә. Мәктәп бинасында 78 кешегә диспансеризация үткәрелде: терапевт, невропатолог, уролог кабул итте, ЭКГ, УЗИ ясалды, кан анализы алынды. 72 кеше учетта тора, алардан елга 2 тапкыр кан алынды, ЭКГ ясалды. Барлыгы 205 кешегә медпункт шартларында ЭКГ тикшерүе үткәрелде. Флюорография машинасы килеп 57 кешенең үпкәләренә тикшерү үткәрде, 43 кеше Азнакайда поликлиникада үтте. Хатын-кызлар врачы килеп 45 кеше каралды. Участок терапевты 4 мәртәбә килде. 110 кеше гриппка каршы прививка алды, 350 тапкыр тонометрия ясалды.Социаль яклау идарәсеннән бирелгән машина белән 45 кешегә медосмотр үткәрелде. Шулай ук фельдшерыбыз балалар һәм өлкәннәр белән төрле профилактик чаралар, авыруны булдырмау ысулларын өйрәтеп тематик сөйләшүләр үткәрә, бик зур рәхмәт.

Авыл клубында 1 кеше эшләде. (слайд) Театр, спорт, җыр, бию, чигү түгәрәкләре эшләп килде. Даими рәвештә дискотекалар оештырылды, яшьләр белән төрле тематик һәм аңлатма эшләре алып барылды. Район күләмендә үткәрелүче барлык конкурслар, смотрлар, күргәзмәләрдә катнаштык. Үткәрелгән барлык бәйрәмнәрдә үзебезнең үзешчән артистларыбыз Мәсгут авылыннан Зиннуров Илгизәр абый (үзенең баяны бәлән) бик матур концерт номерлары, скетчлар куялар. Аларны отчет ахырында әйтеп китәрбез.

Авыл яшьләре арасында тәрбия бирү чарасы буларак һәм тәртип саклау максаты белән оештырылган ирекле халык дружинасы рейдлар ясап тора. Социаль куркыныч тудыручы гаиләләргә даими рейдлар ясала, алар белән тәрбия эшләре алып барыла.

Китапханәдә 1 кеше эшли. Китапханәдә балалар һәм өлкәннәр белән бик күп әдәби чаралар үткәрелә. (Саннарны слайдта күрәсез). 201 кеше язылган, шуларнын 57се балалар (монда кунакка кайткан балалар да керә). Ел дәвамында 3653 китап, газета алынган, шуларнын 1304се балаларга бирелгән. Өлкәннәргә рус телендә 1833, татар телендә 1820 китап бирелгән. Китапханә 17 төрле газета-журнал яздырып ала. “Яңа китаплар сезнең өчен, балалар” дигән темага әңгәмәләр, Г.Тукай, Р.Батулла, Р.Бәшәр иҗатларына багышлап викториналар, 2023 елның юбиляр китапларына күзәтүләр үткәрелә. 2023 елда иң күп китап укучылар: Марат-Нурия Баевлар, Тухватуллина Мәрьям, Билалова Асия апалар.

5 сентябрьдә Азнакай шәһәренең үзәк китапханәсендә Тәрхан авылында яшәп иҗат итүче шагыйрәбез Гафифә апа Гаффарованың 75 яшьлек юбилее уздырылды.

Китапханә мөдире белән клуб мөдире район үзәгендә уздырылучы әдәби, мәдәни чараларда да бик актив катнашып, төрле мактау грамоталары алалар. (слайд) Район мәгариф, мәдәният идарәләренең үзара килештерелгән планнарына нигезләнеп, 2023 елның җәендә авыл китапханәләре һәм клублары каршында балалар өчен җәйге ЛАГЕРЬ оештырылды. (слайд) 3 атна дәвамында авылыбызда яшәүче балалар белән беррәттән әби-бабаларына кунакка кайткан балалар да көннәрен кызыклы, файдалы итеп үткәрделәр. Гөлүсә апа белән Роза апа балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә матурлыкны күрергә, гореф-гадәтләребезне саклап, мәдәни чараларда катнашып, күңел рухлыгын югалтмыйча яшәргә өйрәтәләр, рәхмәт аларга.

<u>Почта бүлекчәсендә</u> 1 хезмәткәр эшли. Ул 4 авылга хезмәт күрсәтә: 35 пенсионерга пенсия, субсидия акчалары тарата. 2нче яртыеллыкка барлыгы 157 данә басмага яздыру (подписка) оештырылды.

Почта, китапханә һәм ФАП хезмәткәрләре белән кече авылларга 2 атнага 1мәртәбә выездлар ясала. (слайд) Халык белән күрешү, аралашу, килеп туган проблемаларны барлау оештырыла.

Югарыда әйтелгән бюджет учреждениеләреннән тыш, авыл җирлегендә хатын-кызлар, ветераннар советлары да эшләп килә. Ветераннар Советы рәисе Мәрдәншина Зилира апа өлкәннрнең гозерләрен, аларнын мөрәҗәгатьләрен вакытында безгә житкереп тора, һәрбер чарада бик актив катнаша, өлкәннәребезнең юбилей-туган көннәрен барлап, хәбәр итеп тора. Бик зур рәхмәт аңа.

Бюджет учреждениеләрендә эшләүче хезмәткәрләр, ветераннар бердәм булып, авылдагы барлык чаралар да оешкан төстә үтә. Физик көч, техника кирәк булган чараларда Агрофирма хезмәтчәннәре даими ярдәм итәләр. Агрофирма ярдәме бик зур. Һәм без үз чиратыбызда аларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырышабыз: көзге айларда амбарда ярдәм итү кебек эшләрдә катнашабыз. Ветераннарыбыз да калышмый, алар да көчләреннән килгәнчә ярдәм итәләр.

<u>Ел дәвамында уздырылган чаралар:</u>

- Елдагыча Кышкы спартакиада уеннары . Ел башыннан атна саен сайлап алу турларында катнаштык. Һәрбер уенчының сәламәтлеген тикшерү нәтиҗәсе һәм бәла-казалардан иминиятләштерү полисы белән катнаштырдык. Карамалы авылында узган 12нче спартакиадада катнаштык. Барлык уеннарда катнашып үзебезнең нәтиҗәләрне күрсәттек. Катнашучыларны сабантуйда бүләкләдек.
- Еллык отчет җыелышы уздырылды .
- Районда уздырылган узешчән артистларнын смотр конкурсында катнаштык.
- Районда ел саен ветераннарыбыз өчен уздырылучы “Ворошиловский стрелок” дип аталган төз ату ярышлары Советлар Союзы Герое, Әкрам Вәлиевка багышланган иде. Анда катнашып, авылдашыбызны искә алдык

- Икенче ел рәттән, традициягә әйләнеп баручы “Бәлеш бәйрәме”н үткәрдек. Әлеге чара турында районлашларыбыз да “Маяк” газетасыннан укып белә алды.
- Язгы эшләр алдыннан техиканы кабул иту комиссиясен каршылап, “Азнакай” Агрофирмасы эшчеләре әзерлекләрен күрсәттеләр.
- Бөек Җиңү бәйрәме уңаеннан сугыш чоры балаларына бүләк-пакетлар тапшырылды. Ветеран һәм тыл хезмәтчәннәренә котлау открыткалары таратылды
- Бөек Җиңү бәйрәмен каршылап, Илбәк һәм Ирекле авылларында һәйкәлдә митинглар үткәрелде. Балалар белән кошлар көне, сәламәтлек көне, Тукайга багышланган кичәләр уздырылды.
- Мәчетебездә Ураза, Корбан гаетләре бик матур итеп узды.
- Мөслимов Илгиз Рәшит улының гаиләсе исеменнэн мәктәптә зурлап ифтар ашы уздырылды.
- Соңгы кыңгырау бәйрәмнәре Кәкре-Елга һәм Илбәк авылларында үткәрелде.
- 1июнь – балалар яклау көнендә авылыбызның ял итү зонасында Балалар өчен кече сабантуй оештырылды.
- Илбәк һәм Ирекле авылларында Сабантуй бәйрәмен уздырдык.
- Район Сабантуенда Ирекле авылынннан Закирова Далия апа “Иң яхшы староста” номинациясендә җиңү яулады.
- Районыбыз ел да үткәрелүче “Чатыр-тау” жыенында самоварлар күргәзмәсе белән катнаштык
- 10 класс укучысы Габдрахимов Раил район күләмендә беренче тапкыр оештырылган шахмат турнирында катнашып, үз көчен сынады.
- 1сентябрь – Белем көне. Елдагыча, һәр балага бүләкләр тапшырылды.
- 28 сентябрьдә Мәүлид кичәсе буларак, мөнәҗәтләр әйтеп башланган бәйрәмебез өлкәннәрне хөрмәтләү чарасы буларак, җыр-биюләр, чәй табыны белән дәвам итте.
- Ноябрь азагында Әниләр көнен билгеләп үттек.
- Каз өмәсе йоласы бик зурлап, Ирекле авылында, Закирова Далия апа гаиләсендә уздырылды. Видеролик районкүләм конкурска җибәрелде.
- Инвалидлар органнары кысаларында мөмкинлекләре чикле авылдашларыбызга пакетлар таратылды.
- Шулай ук инвалидлар унконлегенә багышланган марафонда катнашып, үз өлешебезне кертеп кайттык.
- Авылыбыз уртасында урнашкан ял итү зонасында бик матур итеп яңа ел бизәлеше ясалды.
- Балалар бакчасына йөрмәүче балаларга бүләкләр таратылды.
- 30 декабрь конне күңелле итеп Яна ел балмаскарадын үткәрдек.

Авылдагы барлык массакүләм мәдәни чаралар күмәк көч белән, оешкан төстә үтәләр.

2024 ел Россиядә “ Гаилә елы”, җөмһүриятебездә “Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы” дип игълан ителде.

2024 елга куелган максатлар:

- кече авылларда блок-модульле кибетләр торгызу өчен республикада игълан ителгән “Авыл кибете” программасы нигезендә Илбәк авылында яңа кибет булдыру. Бу максаттан ел дәвамында җирне документлаштыру эшләре алып барылды. Иске кибет сүтелде, төзелеш калдыкларыннан җирне чистартып, ул урын тигезләп куелды.

- “Агросила” холдингы икенче ел рәттән авыл җирлекләрен социаль үстерү программасы буенча конкурс игълан итә. Быел безнең авыл җирлеге “Чишмәләрне төзекләндерү” номинациясендә катнаша. Яңа кибет янәшесендә төзекләндерелгән чишмә авылыбызга бер ямь биреп торыр дип өметләнәбез.

- үзарасалым акчасын вакытында җыеп, республика ярдәме белән, каралган эшләрне соңармыйча башкарып чыгу бурычы тора.

- Тархан авылына газ кертү буенча проектлар өчен информация җыю һәм республика программасына кереп, эшне башкарып чыгуга ирешү.

Шулай ук бүгенге көндә зур проблемаларыбыз да юк түгел:

- Тырыш һәм Тархан авылларының юллары начар хәлдә.
- Илбәкнең сууткәргеч торбалары начар хәлдә, гел ремонт таләп итәләр.

Әлеге проблемаларны хәл итүдә районыбыз җитәкчелегеннән ярдәм көтеп калабыз.

Республикада эшләп килүче күпсанлы программаларда катнашу мөмкинлеге тудырган өчен Татарстан Республикасы Рәисенә, районыбыз башлыгы Марсель Зөфәр улы Шәйдуллинга һәм аның бердәм җитәкчелек командасына рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез. Авылларыбызның проблемаларын белеп торучы, аларны район дәрәҗәсендә чишәргә, уңай якка хәл итәргә безгә һәрчак ярдәмгә килүче кураторыбыз Хәлиуллин Айдар Фәндәсовичка барыбыз исеменнән рәхмәт сүзләрен җиткерәбез. “Азнакай” Агрофирмасы” җитәкчелегенә һәм безнең бүлекчәдә эшләүче барлык хезмәтчәннәргә, егетләребезгә рәхмәт , шулай ук менә шушы бинада хезмәт куючы, бюджет оешмаларында эшләүче кызларга рәхмәт . Иң зур рәхмәтебезне бердәм авыл халкына белдерәм.

Бөтенебез бергә дус, күмәк булганда, киләчәктә дә шулай бергә эш алып барылса, авылыбыз матур яшәр дип өметләнеп калабыз. Республика, районыбыз җитәкчелегеннән күрсәтелгән зур ярдәмне тоеп яшибез.

Киләчәгебез дә шулай матур булсын, булган тормышыбызга шөкер итеп, сәламәтлек белән яшәргә язсын. Елларыбыз тыныч, күк йөзебез аяз булсын, һава торышлары әйбәт булып игеннәребез уңсын, гаиләләребез, якыннарыбыз, дусларыбыз , авылдашларыбыз, күршеләребез белән тату булып яшәргә язсын барчабызга да.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.